РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«22» гыйнвар 2020 ел Олы Кайбыч ав. № 214

«Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының җирле үзидарә сайланулы органнарының үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы әгъзаларының, контроль-хисап органнары рәисләренең, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү нормативлары күләме, айлык һәм башка өстәмә түләүләр, һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибе турында» 2018 елның 23 апрелендәге 121 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Социаль гарантияләрне тәэмин итү, даими нигездә муниципаль вазыйфа биләүче затларга хезмәт өчен түләүне тәртипкә салу һәм камилләштерү, аларның һөнәри хезмәт эшчәнлеген стимуллаштыру максатларында, «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, контроль-хисап органнары рәисләренең хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында»

1. «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларының, җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларының, контроль-хисап органнары рәисләренең, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәткә түләү күләме, айлык һәм башка өстәмә түләүләрне һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибе турында» Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советының 2018 елның 23 апрелендәге 121 номерлы (2018 елның 14

декабрендәге 144 номерлы үзгәрешләре белән) расланган карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5 нче кушымтаның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Хезмәт өчен түләүнең билгеләнгән фонды чикләрендә аеруча мөһим һәм катлаулы биремнәрне үтәгән өчен муниципаль хезмәткәрләргә премияләр түләү (алга таба премияләр) әлеге Тәртип нигезендә кабул ителгән җирле үзидарә органы һәм муниципаль орган бурычларын һәм функцияләрен тәэмин итүне исәпкә алып, ай саен һәм эш нәтиҗәләре буенча җирле үзидарә органы җитәкчесе (җирле орган) карары буенча ел дәвамында башкарыла..».

Әлеге карарның гамәлдә булуы 2020 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Кайбыч муниципаль районы сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында pravo.tatarstan.ru урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Кайбыч муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына йөкләргә.

Совет Рәисе А.И.Рәхмәтуллин